МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.02.2021 Казан шәһәре № 40

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламентына үзгәреш кертү турында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартындагы 135 номерлы, 2015 елның 28 июлендәге 346 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 177 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге 385 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы 23 номерлы, 2020 елның 29 апрелендәге 221 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламентына үзгәреш кертеп, аны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
26.03.2013 № 96 боерыгы белән
расланды (Татарстан
Республикасы Икътисад
министрлыгының 03.02.2021
№ 40 боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламенты (алга таба – Регламент) кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен (алга таба – лицензия контроле) гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан башкарыла торган административ процедураларның, административ гамәлләрнең срокларын, эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең атамасы: кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру (алга таба – дәүләт функциясе).

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУЧЫ

1.2. Дәүләт функциясен башкаручы булып Министрлык тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручы булып Министрлыкның Административ реформа мәсьәләләре идарәсенең лицензияләү бүлеге (алга таба – Бүлек) тора.

Дәүләт функциясе тикшерү уздыру турында Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык нигезендә вәкаләт бирелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт функциясен үтәү Министрлыкның түбәндәгеләр белән үзара бәйләнешендә гамәлгә ашырыла:

- планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрүне килештерү, планлы тикшерүләр үткәрү планнарын килештерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнары (алга таба – прокуратура органнары) белән;

- дәүләт хакимияте органнары, юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар тарафыннан аларның мөрәҗәгатьләре буенча;

- контрольлек чараларын үткәрүгә җәлеп итү максатларында Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә махсус белеме, тәҗрибәсе булган, шәхси эшкуарлар булып тормаган эксперт – гражданнар белән;

- илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитация узган һәм контрольлек чараларын уздыруга Министрлык тарафыннан җәлеп ителә торган эксперт оешмалары – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән.

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры) мәгълүмат кертү билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕ ҖАЙГА САЛУЧЫ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт функциясетүбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №19, 2716 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №1, 26 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 369 номерлы карары белән расланган Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре (алга таба – Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү

кагыйдәләре) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 21, 2083 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 370 номерлы карары белән расланган Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре (алга таба – Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, №21, 2084 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №28, 3706 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1287 номерлы карары белән расланган Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турындагы нигезләмә (алга таба – Лицензияләү турында нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №51, 7222 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан контрольлек чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 636 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, №29, 4142 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №44, 6127 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә дә, әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу

турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 №17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, 2017, 21 март);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 19 ноябрендәге 812 номерлые карары белән расланган Физик затлардан кабул итүгә рөхсәт ителгән төсле металл ватыклары һәм калдыклары исемлеге  (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 812 номерлы карары белән расланган исемлек) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2008, №14, 0528 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик затлардан кабул итү өчен тыела торган, көнкүрешнекенә карамаган кара металл ватыклары һәм калдыклары исемлеген раслау турында» 2003 елның 11 сентябрендәге 486 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 486

номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2003, №19, 59 статья);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары (алга таба – 325 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №30, 1057 сатья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Лицензия алырга теләүче зат яки кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булган, шул исәптән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба – лицензия алырга теләүчеләр, лицензиатлар) эшчәнлеге лицензия контроле объекты булып тора.

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ПРЕДМЕТЫ

1.5. Лицензия алырга теләүче затлар һәм лицензиатлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән лицензия таләпләрен үтәү лицензия контроленең предметы булып тора.

## ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА МИНИСТРЛЫК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ ӨЧЕН ХОКУКЛАР, БУРЫЧЛАР ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР

1.6. Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары лицензия контролен гамәлгә ашырганда хокуклы:

1) тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә дә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган Исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында салым серен яисә законда саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны соратырга, – тиешле белешмәләрне тикшерүнең лицензия алырга теләүче затлар, лицензиатлар тарафыннан зарури таләпләр үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм әлеге белешмәләрне тапшыру федераль законда каралган булуы шарты белән;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны тапшырырга, аларны ачарга, шул исәптән, законнарда карал-

ган очракларда, алар белән танышып чыгарга, дәүләт сере һәм законда саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясенең законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырырга;

4) лицензия алырга теләүчеләрдән һәм лицензиатлардан лицензия контролен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган һәм тапшырылуы Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне һәм документларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

5) лицензия алырга теләүчеләргә һәм лицензиатларга тикшерүләр үткәрергә;

6) лицензиатларга тикшерү барышында ачыкланган лицензия таләпләре бозылу очракларын бетерү турында күрсәтмәләр бирергә;

7) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә зарури таләпләр бозылуга юл куймау турында кисәтүләр бирергә;

8) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ачыкланган бозулар турында белешмәләрне вәкаләтле органнарга җибәрергә.

1.7. Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары лицензия контролен гамәлгә ашырганда бурычлы:

1) лицензияләү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган, шул исәптән зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча да, вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырыла торган лицензия алырга теләүчеләрнең һәм лицензиатларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) тикшерү билгеләнүенә бәйле рәвештә министр, министр урынбасарының аны уздыру турындагы боерыгы нигезендә тикшерү үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт бурычларын үтәгәндә генә үткәрергә, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, министрның, министр урынбасарының тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен һәм, 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 10 өлешендәге 2 пунктында каралган очракта, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турындагы документ күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрергә;

5) лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерүне үткәргәндә катнаша торган лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) лицензия алырга теләүченең, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) лицензия алырга теләүченең, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның бозуларның авырлыгына, аларның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия

Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган, илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характерлы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә булган потенциаль хәтәрлелегенә туры килүен исәпкә алырга, шулай ук граждан-нарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

10) лицензия алырга теләүчеләр, лицензиатлар тарафыннан шикаять белдерелгәндә үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерү уздыруның 294-ФЗ номерлы Федераль законда һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән срокларын сакларга;

12) лицензия алырга теләүчедән, лицензиаттан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

13) күчмә тикшерү уздыра башлар алдыннан лицензия алырга теләүченең җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, лицензиатның гозере буенча аларны тикшерү уздыруга нигез булган әлеге Регламент кушымталары белән таныштырырга;

14) лицензия алырга теләүчедә, лицензиатта булган очракта, уздырылган күчмә тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (тикшерүләрне исәпкә алу журналының үрнәк формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган) теркәргә.

1.8. Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары лицензия контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) әгәр бу таләпләр Министрлык вәкаләтләренә карамаса, Министрлык исеменнән гамәл кылучы вазыйфаи затлар буларак, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр үтәлешен, шулай ук кулланылышы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

4) тикшерү уздырганда лицензия алырга теләүченең, лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, мондый тикшерүне гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган, илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салыну, табигый һәм техноген характерлы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү нигезе буенча үткәрү очраклагыннан тыш, планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

5) тикшерү объектлары булып тормаса яки тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләре тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның оригиналларын алырга;

6) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен әлеге үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документларда һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәмнәр алу кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

7) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән вакытларын арттырырга;

9) лицензия алырга теләүче затларга, лицензиатларга алар хисабыннан контроль чараларны үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

10) лицензия алырга теләүче заттан, лицензиаттан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә;

11) тикшерү уздыра башлау датасына кадәр лицензия алырга теләүче заттан, лицензиаттан документлар, мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә. Министрлык, тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЛИЦЕНЗИЯ АЛЫРГА ТЕЛӘҮЧЕНЕҢ, ЛИЦЕНЗИАТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерү уздырылганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагыла торган һәм тапшырылуы 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

3) документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкка алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматны Министрлыкка үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешү яки килешмәү турында күрсәтергә;

6) тикшерү уздырганда Министрлык вазыйфаи затларының лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның хокуклары бозылуга китерегән гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерү уздырылганда бурычлы:

1) Министрлыкның лицензия контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларына тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча тапшырылуы Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләр һәм документларны, шулай ук телдән һәм язмача аңлатмаларны бирергә;

2) тикшерү уздыруга вәкаләтле затлар өчен лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда кулланыла торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә, лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан кулланыла торган җайланмаларга, шуңа охшаш объектларга, транспорт чараларына үтеп керү мөмкинлеген тудырырга;

3) зарури таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм уздыру өчен җаваплы затлар булуын тәэмин итәргә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯЛӘРЕН ҮТӘҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.11. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 141номерлы боерыгы белән расланган форма буенча 2 нөсхәдә төзелгән, лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының лицензия таләпләре үтәлешен тикшерү акты (алга таба – тикшерү акты);

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

3) лицензия алырга теләүче затта, лицензиатта булган очракта, уздырылган күчмә тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (тикшерүләрне исәпкә алу журналының үрнәк формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган) теркәлгән язу.

лицензия таләпләре бозылу очраклары ачыкланган очракта:

4) бетерү срокларын күрсәтеп, лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган

очракларын бетерү турында һәм (яисә) тиешле чараларны уздыру турында 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында каралган таләпләрне исәпкә алып рәсмиләштерелгән күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә, лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмә) (әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китереп);

алынган мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда әзерләнә торган бозулар турында яки лицензия таләпләрен бозу билгеләре турында мәгълүматлар булган очракта:

5) лицензия таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү;

кирәк булганда:

лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында Министрлык боерыгы;

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында Министрлык боерыгы;

лицензияне гамәлдән чыгару турында арбитраж судына гариза;

6) ачыкланган бозуларны бетерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрү, аларны кисәтү, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, документларына, илкүләм китапханә фонды составына керә торган, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган документларга ихтимал зыянны булдырмый калу, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә.

Дәүләт функциясен үтәү өчен нигез булып Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар алынуы хезмәт иткән булса, дәүләт функцияләрен үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган лицензиат эшчәнлегенең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Министрлык компетенциясенә карамаса, Министрлык мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ ҮТӘЛЕШЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55.

2.2. Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

2.3. Дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне Министрлыкка җибәрү өчен адреслар һәм телефоннар:

Министрлыкның почта адресы:

420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55;

Министрлыкның белешмә телефоннары: 524-91-48, 524-91-49, 524-90-22;

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mert.tatarstan.ru;

электрон почта адресы: mineconom@tatar.ru.

2.4. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре, Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән телефоннар буенча);

2) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән mineconom@tatar.ru электрон почта адресы буенча электрон документ формасында да);

3) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

4) Министрлык биналарында лицензия контроле турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлары аша.

2.5. Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, Министрлык бинасында мәгълүмати стендта бүлек белгече тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла һәм актуаль хәлдә саклана:

- дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагылышлы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләре турында;

- ел саен Министрлык тарафыннан раслана торган хокук бозуларны профилак-тикалау программасы;

- лицензия контроле предметы булып торган зарури таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләре исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

- лицензия алырга теләүче затлар, лицензиатлар өчен лицензия таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән лицензия таләпләрен үтәү буенча басылып чыккан кулланма турында, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү турында мәгълүматлар, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, башка ысуллар белән урнаштырылган башка мәгълүмат турында белешмәләр;

- лицензия таләпләре исемлеге, шулай ук алар үзгәргән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән лицензия таләпләрен билгеләүче яңа норматив хокукый актлар-ның эчтәлеге, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар,

шулай ук зарури таләпләрне гамәлгә кертү һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр;

- лицензия контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елына бер тапкырдан да ким түгел), шул исәптән, мондый хокук бозуларга юл куймас өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән лицензия таләпләрен бозуның еш очрый торган очракларын, шул исәптән мондый хокук бозуларга юл куймау максатларында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларны да күрсәтеп;

- әлеге Регламент;

- Министрлык боерыгы белән расланган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – План);

- Министрлыкның урнашу урыны, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, электрон почта адресы;

- дәүләт функциясен үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган гамәлләргә һәм (кабул ителгән) карарларга (гамәл кылмауга) шикаять белдерү тәртибе;

- дәүләт функциясен башкарганда гамәлләр эзлеклелеген чагылдыра торган блок-схема.

2.6. Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап, тиешенчә, күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска, 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Министрлыкта әлеге мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып, календарь көннәрендә исәпләнелә торган утыз көнлек срокта җибәрелә.

Телефон аша мөрәҗәгатьне кабул иткән Министрлыкның вазыйфаи заты куелган сорауларга җавап бирә алмаса, телефон аша җиткерелгән мөрәҗәгать башка вазыйфаи затка адреслана (күчерелә) яки мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүмат алу мөмкинлеге булган башка телефон номеры турында хәбәр ителә.

## ЛИЦЕНЗИЯ АЛЫРГА ТЕЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРДАН, ЛИЦЕНЗИАТЛАРДАН КОНТРОЛЬ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАВЫ

2.7. Лицензия алырга теләүче затлардан, лицензиатлардан тикшерү чараларын үткәргән өчен түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләр үткәрүгә аларны җәлеп иткән очракта, эксперт һәм эксперт оешмалары күрсәткән хезмәтләр өчен дә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ВАКЫТЫ

2.8. Һәр тикшерүне (планлы, планнан тыш, күчмә, документар) үткәрү вакыты егерме эш көненнән артмаска тиеш.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планлы тикшерү үткәрү вакыты аны үткәрү датасыннан алып унбиш эш көненнән дә артмый.

Кече эшкуарлык субъекты булып торган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен ун сәгатьтән артмаска тиеш. Тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшерүләр һәм экспертизалар үткәрү зарурилыгы белән бәйле аерым очракларда тикшерү үткәрү вакыты озайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата – иң күбе утыз сәгатькә кадәр генә, микропредприятиеләргә карата – иң күбе ун сәгатьтән кадәр генә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең башка резидентларына карата – иң күбе унбиш эш көненә кадәр генә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планнан тыш тикшерү үткәрү вакыты биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.9. Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, Министрлыкның урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү вакыты министр тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

2.10. Кече эшкуарлык субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурлыгы килеп чыккан очракта, министр (министр урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе ун эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, башка объектларында Министрлыкның күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

2.11. Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы лицензиатка карата тикшерү (документар, күчмә) уздыру вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерү уздыруның гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артык була алмый.

2.12. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.13. Планлы тикшерүләр Министрлык тарафыннан әзерләнә һәм раслана торган планлы тикшерүләр планы (алга таба – План) нигезендә үткәрелә. Министр

раслаган План Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын тикшерүнең еллык план проекты Министрлык тарафыннан әзерләнә һәм 473-ФЗ номерлы Федераль закон, 1132 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә вәкаләтле федераль органга килештерү өчен һәм 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә прокуратура органнарына килештерү өчен җибәрелә.

2.14. Лицензиатларны планлы тикшерүләр үткәрелә:

1) лицензия бирү турында карар кабул ителгән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган чорда;

2) соңгы планлы тикшерү уздырылган көннән соң өч ел узмаган чордан да иртәрәк түгел.

2.15. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1) лицензиат тарафыннан элегрәк бирелгән лицензия таләпләрен бозу очракларын бетерү турында Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы бетү, бу очракта тикшерү предметы бары тик Министрлык биргән күрсәтмә үтәлеше генә булырга мөмкин;

2) Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан лицензиатның лицензия таләпләрен тупас бозу фактлары турында мәгълүмат алынуы;

3) 99-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләренә ярашлы рәвештә лицензиянең гамәлдә булуы туктатылган вакыт узуы;

4) Министрлык күрсәтмәсен вакытыннан алда үтәү фактын билгеләү максатларында, Министрлык тарафыннан планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында лицензиаттан үтенеч булуы;

5) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәләре нигезендә чыгарылган Министрлык боерыгының булуы;

6) лицензия алырга теләүче затның лицензия бирү турында яисә лицензиатның лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза тапшыруы (99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 һәм 18 статьяларында каралган очракларда, Министрлык тарафыннан, билгеләнгән тәртиптә прокуратура органы белән килештермичә, документар тикшерүләр һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрелә).

2.16. Кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген башкарганда лицензия таләпләрен тупас бозу исемлеге Лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә. Шул ук вакытта лицензия таләпләрен бозу очракларына түбәндәгеләргә сәбәпче булган җитешсезлек очраклары да кертелергә мөмкин:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә) зыян салыну куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүе;

б) кеше корбаннары яисә гражданнар сәламәтлегенә авыр зыян китерү, ике һәм аннан күбрәк гражданинның сәламәтлегенә уртача авырлыкта зыян китерү,

хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә) зыян китерү, техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, гражданнарның хокукларына, законлы мәнфәгатьләренә, ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә зыян китерү.

2.17. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Регламентның 2.15 пунктының 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була ала икән, планнан тыш тикшерү бары тик Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләү мөмкинлеге булган очракта гына үткәрелергә мөмкин. Мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карала.

| | г) Россия Федерациясе субъекты территориясе чикләрендә кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү объектларының кимендә берсендә түбәндәге төр җайланмаларының теләсә кайсыннан берәр берәмлек булуы:<br>кара металл ватыкларын пакетлау өчен тыгызлагыч;<br>тыгызлагыч-кайчы;<br>җиңел металл ватыкларын кисү һәм сортировкалау җайланмасы;<br>йомычкаларны сортировкалау яки ваклау өчен җиһаз;<br>- металл вату өчен копер. | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 8(1) пунктының «г» пунктчасы | Лицензия алырга теләүче затта милек хокукында яисә законлы башка нигездә кара металл ватыкларын пакетлау өчен пресс яисә пресс-кайчы, яисә җиңел металл ватыкларын ваклау һәм сортлау өчен җайланма яисә йомычкаларны сортлау яки ваклау өчен җайланма яки<br>металл ватыкларын вату өчен копер булуын раслаучы документларны һәм техник документларның күчермәләре |
| | 2) кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү ватыкларның һәм калдыкларның һәр партиясенә кабул итү-тапшыру актын зарури төзеп гамәлгә ашырыла. | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү | Кабул итү-тапшыру актлары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | Кабул итү-тапшыру акты 2 нөсхәдә кәгазьдә (1 нөсхәсе кара металл ватыкларын һәм калдыкларын тапшыручы затка тапшырыла, 2 нөсхәсе кабул итүче затта кала) яисә, көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга кулланып, электрон документ рәвешендә төзелә. | кагыйдәләренең 10 пункты | |
| | 3) кабул итү-тапшыру актлары кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсендә теркәлә (алга таба – исәпкә алу китабы).<br>Исәпкә алу кенәгәсен электрон рәвештә алып бару рөхсәт ителә. | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 11 пункты | Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсе |
| | **Читләштерелә торган кара металл ватыкларын һәм калдыкларын исәпкә алу тәртибе** | | |
| | төяп озатылган кара металл ватыклары һәм калдыкларының һәр партиясе читләштерелгән кара металл ватыкларын һәм калдыкларын теркәү журналында теркәлергә тиеш.<br>Төяп озатылган кара металл ватыкларын һәм калдыкларын электрон рәвештә теркәү журналын алып бару рөхсәт ителә. | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 18 пункты<br>Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 19 пункты | Төяп озатылган кара металл ватыкларын һәм калдыкларын теркәү журналы |

3.2. Лицензиатлар тарафыннан лицензия таләпләре бозылу очракларын кисәтү, лицензия таләпләре бозылуга сәбәпче булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, Министрлык, ел саен раслана торган бозуларны кисәтү программасына туры китереп, лицензия таләпләре бозылуны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Министрлыкта алынган, лицензия таләпләрен бозарга әзерләнү очраклары турында яки бозу билгеләре турында мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) булган мәгълүматлар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат булган очракта, лицензия таләпләрен бозуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының уникаль, шул исәптән уникаль, документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган һәм илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерүе, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгаруы яисә әлеге нәтиҗәләр килеп чыгу хәҗәрен барлыкка китерүе турында расланган белешмәләр булмаса, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләрен бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләре үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кисәтүдә билгеләнгән чорда Министрлыкка хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Лицензия таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар белдерү һәм аларны Министрлык тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүне үтәү турында Министрлыкка хәбәр итү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЛИЦЕНЗИЯ АЛЫРГА ТЕЛӘҮЧЕ ЗАТЛАР, ЛИЦЕНЗИАТЛАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелде.

3 нче таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| **Лицензия алырга теләүче затлар, лицензиатлар тарафыннан тикшерү вакытында тапшырыла торган документлар исемлеге** | **Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт** |
|---|---|

| Төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау һәм сату | |
|---|---|
| 1. Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр тапшырыла) җир кишәрлекләренең, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре;<br>Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган техник чараларның, җайланмаларның һәм лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник документларның булуын раслый торган документларның күчермәләре | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы |
| 2. Лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) белән төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә хезмәт килешүләре төзелгән хезмәткәрләрнең квалификацияләрен раслый торган документларның күчермәләре;<br>Төсле металл ватыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре таләпләренә туры китереп лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) җитәкчесе раслаган ватыкларга һәм калдыкларга радиация контролен уздыру һәм ватыкларга һәм калдыкларга шартлау хәтәрлеге буенча контроль уздыру өчен җаваплы затлар билгеләү турындагы документларның күчермәләре; | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| 3. Төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итүнең һәр объектында карап чыгу өчен мөмкинлекле урында булган түбәндәге мәгълүмат булуы:<br>а) юридик зат өчен – атамасы һәм төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), телефон номеры, шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), телефон номеры;<br>б) юридик затлар өчен – төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>в) эш тәртибе;<br>г) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре;<br>д) ТР Министрлар Кабинетының 812 номерлы карары белән расланган Физик затлардан кабул итү өчен рөхсәт ителгән төсле металл ватыклары һәм калдыклары исемлеге | - |
| 4. Булган җиһазларга һәм приборларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынаулар үткәрү турында документлар | - |
| 5. Төсле металл ватыклары һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү һәм шартлау куркынычсызлыгы буенча тикшерү тәртибе турында кулланма | - |

| | |
|---|---|
| 6. Радиоактив төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын ачыклаганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 7. Шартлау куркынычы булган әйберләр табылганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 8. Металл ватыгы тапшыра торган физик зат гаризасы | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 9. Кабул итү-тапшыру актлары | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 10. Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсе | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 11. Төяп озатылган төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын теркәү журналы | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| **Төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | |
| 1. Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр тапшырыла) җир кишәрлекләренең, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре;<br>Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган техник чараларның, җайланмаларның һәм лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник документларның булуын раслый торган документларның күчермәләре | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы |
| 2. Лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) белән төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә хезмәт килешүләре төзелгән хезмәткәрләрнең квалификацияләрен раслый торган документларның күчермәләре;<br>Төсле металл ватыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре таләпләренә туры китереп лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) җитәкчесе раслаган ватыкларга һәм калдыкларга радиация контролен уздыру һәм ватыкларга һәм калдыкларга шартлау хәтәрлеге буенча контроль уздыру өчен җаваплы затлар билгеләү турындагы | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |

| | |
|---|---|
| документларның күчермәләре; | |
| 3. Төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итүнең һәр объектында карап чыгу өчен мөмкинлекле урында булган түбәндәге мәгълүмат булуы:<br>а) юридик зат өчен – атамасы һәм төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), телефон номеры, шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), телефон номеры;<br>б) юридик затлар өчен – төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>в) эш тәртибе;<br>г) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре;<br>д) ТР Министрлар Кабинетының 812 номерлы карары белән расланган Физик затлардан кабул итү өчен рөхсәт ителгән төсле металл ватыклары һәм калдыклары исемлеге | - |
| 4. Булган җиһазларга һәм приборларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынаулар үткәрү турында документлар | - |
| 5. Төсле металл ватыклары һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү һәм шартлау куркынычсызлыгы буенча тикшерү тәртибе турында кулланма | - |
| 6. Радиоактив төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын ачыклаганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 7. Шартлау куркынычы булган әйберләр табылганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 8. Металл ватыгы тапшыра торган физик зат гаризасы | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 9. Кабул итү-тапшыру актлары | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 10. Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсе | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 11. Төяп озатылган төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын теркәү журналы | Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| **Кара металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату** | |
| 1. Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр тапшырыла) җир кишәрлекләренең, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы |

| | |
|---|---|
| (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре;<br>Лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә анықы булган техник чараларның, җайланмаларның һәм лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник документларның булуын раслый торган документларның күчермәләре | |
| 2. Лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) белән кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә хезмәт килешүләре төзелгән хезмәткәрләрнең квалификацияләрен раслый торган документларның күчермәләре;<br>Кара металл ватыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре таләпләренә туры китереп лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) җитәкчесе раслаган ватыкларга һәм калдыкларга радиация контролен уздыру һәм ватыкларга һәм калдыкларга шартлау хәтәрлеге буенча контроль уздыру өчен җаваплы затлар билгеләү турындагы документларның күчермәләре; | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| 3. Кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итүнең һәр объектында карап чыгу өчен мөмкинлекле урында түбәндәге мәгълүмат булуы:<br>а) юридик зат өчен – атамасы һәм төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), телефон номеры, шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), телефон номеры;<br>б) юридик затлар өчен – кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү өчен җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>в) эш тәртибе;<br>г) кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре | - |
| 4. Булган җиһазларга һәм приборларга документлар, шулай ук аларны тикшерү һәм сынаулар үткәрү турында документлар | - |
| 5. Кара металл ватыклары һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү һәм шартлау куркынычсызлыгы буенча тикшерү тәртибе турында кулланма | - |
| 6. Радиоактив кара металл ватыкларын һәм калдыкларын ачыклаганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 7. Шартлау куркынычы булган әйберләр табылганда эш тәртибе турында кулланма | - |
| 8. Кабул итү-тапшыру актлары | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 9. Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсе | Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |
| 10. Төяп озатылган кара металл ватыкларын һәм калдыкларын | Кара металл ватыклары һәм |

| | |
|---|---|
| теркәү журналы | калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН ФОРМАДА ДА ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Дәүләт функциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

тикшерүләр үткәрүне планлаштыру;

планлы күчмә тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә тикшерү уздыру;

лицензия таләпләре бозылу очракларын бетерү буенча чаралар күрү.

Планлы тикшерү күчмә тикшерү формасында үткәрелә. Планнан тыш тикшерү документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата лицензия контроле әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.2. Лицензия контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру блок-схемасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

### «ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.3. Административ процедураны башлап җибәрү өчен еллык тикшерүләр планын әзерләү вакытының килеп җитүе нигез булып тора.

5.4. План Бүлек тарафыннан 294-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары нигезендә әзерләнә.

5.5. Планлы тикшерүләр лицензиатларга карата үткәрелә. Лицензиатны план буенча тикшерүне еллык Планга кертү өчен әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.6. Бүлек җитәкчесе План әзерләү буенча җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) (алга таба – План әзерләү буенча җаваплы башкаручы) билгели.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 1 июленә кадәр.

5.7. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

1) РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән билгеләнгән форма буенча план проектын төзи;

2) аны министр, министр урынбасары белән килештерә;

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 20 августына кадәр;

3) План проектын карау өчен үзләренә карата планлы тикшерүләрне уздыру планлаштырыла торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар урнашкан урын буенча кәгазьдә (күчермәсен электрон формада теркәп) кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында прокуратура органнарына җибәрә;

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 1 сентябренә кадәр.

5.8. План проектын тикшергәннән һәм тәкъдимнәр керткәннән соң, План әзерләү буенча җаваплы башкаручы ачыкланган кисәтүләрне бетерүне оештыра һәм План министр тарафыннан расланганнан соң аны прокуратура органнарына җибәрә.

Үтәү вакыты: расланган Планны прокуратура органнарына җибәрү – планлы тикшерүләрне уздыру елыннан алда килүче елның 1 ноябренә кадәр.

5.9. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы расланган Планны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыруны оештыра.

Үтәү вакыты: план расланган вакыттан башлап 5 эш көне эчендә.

5.10. РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда, раслаучы документлар булганда, Планга үзгәрешләр кертү рөхсәт ителә.

Планга үзгәрешләр кертү Министрлык боерыгы белән башкарыла. Кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр алар кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) тиешле кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына җибәрелә, шулай ук үзгәрешләр кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

## «ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.11. «Планлы күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен тиешле лицензиатны ел саен төзелә торган планга кертү һәм лицензиатка карата планлы күчмә тикшерү үткәрү вакытларының килеп җитүе нигез булып тора.

Лицензиатка карата планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

5.12. Лицензиатка карата планлы тикшерүләр предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, эшчәнлекнед лицензияләнә торган төрен башкарганда файдаланыла торган бүлмәләрнең, биналарның, корылмаларның, техник чараларның, җайланмаларның, башка объектларның торышы турындагы

белешмәләр, лицензиат хезмәткәрләренең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең, лицензия таләпләрен үтәү буенча лицензиат тарафыннан күрелә торган чараларның лицензия таләпләренә туры килүе тора.

5.13. Күчмә (планлысы да, планнан тышы да) тикшерү лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның эшчәнлек төрен фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

5.14. «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;

2) тикшерү уздыру турында боерык рәсмиләштерү;

3) лицензиатка тикшерү үткәрелүе турында хәбәр итү;

4) тикшерү үткәрү;

5) тикшерү акты рәсмиләштерү;

5.15. Ел саен төзелә торган План нигезендә Бүлек җитәкчесе лицензиатка планлы тикшерү үткәрү өчен җаваплы (җаваплы) вазыйфаи затларны (вазыйфаи зат) билгели (әлеге Регламентның 2.24 пункты).

Күчмә тикшерүне уздырганда экспертларның, эксперт оешмаларының катнашуы таләп ителсә, билгеләнгән тәртиптә экспертлар, үзенә карата тикшерү уздырыла торган лицензиат белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булмаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүне үткәрә башлар алдыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: тикшерү өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге.

5.16. Җаваплы башкаручы планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул куюга җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Тикшерү министр (министр урынбасары) боерыгында күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

Үтәү вакыты: планлы тикшерү үткәрелә башлаганчы дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган планлы күчмә тикшерүне үткәрү турында боерык.

5.17. Җаваплы башкаручы лицензиатка планлы тикшерү үткәреләчәге турында министр (министр урынбасары) боерыгы күчермәсен, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм лицензиатның электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр итә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яки элегрәк лицензиат тарафыннан Министрлыкка җиткерелгән булса, яки үтемле башка ысул белән хәбәр итә.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүне үткәрә башлар алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмыйча лицензиатка хәбәр ителергә тиеш.

Эш нәтиҗәсе: лицензиатка җибәрелгән тикшерү үткәрү турында боерык

күчермәсе.

Лицензиат адресына белдерү җибәрү Министрлыкта эш алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

5.18. Тикшерү бары тик боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

Җаваплы башкаручы күчмә тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

хезмәт таныклыгын күрсәтә;

лицензиатның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, аның вәкаләтле вәкилен түбәндәгеләр белән зарури таныштыра:

тикшерү уздыру турында министр (министр урынбасары) боерыгы белән (министр (министр урынбасары) боерыгының мөһер белән таныкланган күчермәсе) лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә бер үк вакытта хезмәт таныклыкларын күрсәтеп, имзалатып тапшырыла);

күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән;

күчмә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре белән;

контрольлек чараларының төрләре һәм күләме белән;

күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар составы, эксперт оешмалары вәкилләре белән;

аны үткәрү вакыты һәм шартлары белән;

Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча Министрлыкның вазыйфаи затлары үз вәкаләтләрен раслау максатларында Министрлык, контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

5.19. Лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле Министрлыкның күчмә тикшерүне уздыра торган вазыйфаи затларына, әгәр күчмә тикшерүгә документар тикшерү сәбәпче булмаган булса, күчмә тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән танышып чыгу мөмкинлеген бирергә, шулай ук күчмә тикшерүне уздыра торган вазыйфаи затлар һәм күчмә тикшерүдә катнаша торган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган территориягә, биналарга, төзелмәләргә, бүлмәләргә, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла торган җайланмаларга, шуңа охшаш объектларга, транспорт чараларына һәм аларда ташыла торган йөкләргә үтеп керү мөмкинлеген тудырырга тиеш.

Тикшерүләр барышында Министрлыкның вазыйфаи затлары эшчәнлегенә каршылык тудырга бәйле бозулар өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4.1 статьясында административ җаваплылык билгеләнгән.

5.20. Җаваплы башкаручы планлы күчмә тикшерүне үткәрү барышында түбәндәге контрольлек чараларын үткәрә:

- лицензиат документларында аның эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны, кулланыла торган биналар, корылмалар, техник чаралар, җиһазлар, башка объектлар торышын бәяли;

- лицензиат эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән зарури таләпләргә туры килүен, шул исәптән лицензиат хезмәткәрләренең, лицензиат тарафыннан башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең, лицензия

таләпләрен үтәү буенча күрелә торган чараларның лицензия таләпләренә туры килүен бәяли.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгәннәрдән артмый торган, планлы тикшерү үткәрү турында боерыкта күрсәтелгән сроклар.

Эш нәтиҗәсе: үткәрелгән контрольлек чаралары.

5.21. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, №141 боерыгы белән билгеләнгән форма буенча ике нөсхәдә тикшерү акты төзи.

Лицензиат тарафыннан лицензия таләпләрен бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

- зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян салуны чикләү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында тикшерү актына кушымта булып торган күрсәтмәне лицензиатка тапшыра һәм әлеге күрсәтмә үтәлешен контрольдә тота.

Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертиза бәяләмәләре, зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган лицензиат хезмәткәрләренең аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

Тикшерү акты ике нөсхәдә тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яки танышудан баш тарту турында имзалатып тапшырыла, икенчесе (кушымталары белән бергә) Министрлыкта кала торган лицензия эшенә теркәлә.

Лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук лицензиат тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куясы килмәсә, тикшерү акты кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерү Министрлык эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерелә торган затның төбәк лицензия контроле кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты: тикшерү актын тапшыру яки почта аша һәм (яки) электрон документ формасында юллау – тикшерү тәмамланганнан соң.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә тикшерү акты, аның берсе лицензиатка тапшырылган (җибәрелгән) икенчесе лицензия эшенә тегеп куелган.

5.22. Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, экспертиза-ларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның лицензия контроле кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турында белдерү һәм (яисә) әлеге документның алынуына башкача дәлилләмә тикшерү актының Министрлыкта саклана торган лицензия эше нөсхәсенә теркәп куела.

5.23. Җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында язу терки. Тикшерүләрне исәпкә алу журналының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, № 141 боерыгы белән билгеләнгән.

Үткәрелгән тикшерү турындагы язуда Министрлыкның атамасы, тикшерү үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр, шулай ук тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелгән булырга тиеш.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән, номерланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның мөһере (мөһеры булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң.

Эш нәтиҗәсе: тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) яисә тикшерү актында үткәрелгән тикшерү турында тиешле язу.

5.24. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән лицензиат, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Министрлыкка тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта лицензиат мондый ризасызлыкларга әлеге ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

5.25. Әгәр лицензиат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең булмый торуы сәбәпле, яисә лицензиатның фактта эшчәнлегенең гамәлгә ашырылмавы сәбәпле, яисә лицензиат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының, вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты, тикшерүне уздыруның мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, аны уздыруның мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Министрлык, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый лицензиатларга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм лицензиатка алдан хәбәр итмичә, планлы күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.26. «Планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасының үтәлеше Министрлыкның рәсми сайтында, «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, тикшерүләрне исәпкә алу журналында электрон формада теркәлә.

## «ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.27. «Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса.

5.28. Лицензия алырга теләүче затка яки лицензиатка карата документар тикшерү предметы булып, белешмәләрнең 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1 һәм 3 өлешләрендә һәм 18 статьясының 3 өлешендәге нигезләмәләргә, шулай ук лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында һәм башка федераль мәгълүмат ресурсларында булган белешмәләргә туры килүен бәяләү максатларында, тапшырылган гаризаларда һәм документларда булган белешмәләр тора.

Лицензиатка карата документар тикшерү предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен башкарганда файдаланыла торган җир кишәрлекләренең, бүлмәләрнең, биналарның, корылмаларның, техник чараларның, җайланмаларның, башка объектларның торышы турындагы белешмәләр, лицензиат хезмәткәрләренең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең, лицензия таләпләрен үтәү, лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәү буенча лицензиат тарафыннан күрелә торган чараларның лицензия таләпләренә туры килүе тора.

5.29. Планнан тыш документар тикшерү Министрлыкның урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.30. Планнан тыш документар тикшерү әлеге Регламентның 5.14 пунктында күрсәтелгән гамәлләр тәртибе нигезендә башкарыла.

5.31. Әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, Бүлек җитәкчесе әлеге Регламентның 5.15 пункты нигезендә планнан тыш документар тикшерү үткәргән өчен җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.32. Җаваплы башкаручы планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул куюга җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Лицензия алырга теләүче затның лицензия бирү турында яки лицензиатның лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризасы нигезендә планнан тыш документар тикшерү үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы алынган документларны 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13, 18 статьяларында каралган таләпләргә туры килү-килмәве буенча тикшерә.

Бу очракта планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерык проекты лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат тарафыннан лицензия бирү яки аны үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тулы күләмендә тапшырылганнан соң ике эш көне эчендә әзерләнә.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручы билгеләнгәннән соң бер эш көне яки лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат тарафыннан тиешенчә рәсмиләштерелгән гаризаны тапшырганнан соң ике эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык.

5.33. Планнан тыш документар тикшерүне үткәрү барышында җаваплы башкаручы беренче чиратта лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның Министрлык карамагындагы документларын, шул исәптән лицензия эшләрен, алдагы тикшерүләр актларын һәм лицензиатка карата лицензия контроле буенча гамәлгә ашырылган чараларның нәтиҗәләре турындагы башка документларны тикшерә.

5.34. Җаваплы башкаручы:

мәгълүматларның дөреслегенә бәя бирә;

лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның эшчәнлеге зарури таләпләргә туры килү-килмәве буенча документлардагы мәгълүматларга бәяләү уздыра;

кирәк булган очракта, ведомствоара хезмәттәшлек аша мәгълүматлар ала.

Министрлык карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шикләр тудыра икән, яисә бу мәгълүматлар лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан лицензия таләпләре үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, әгәр Министрлыкта тапшырылган һәм анда булган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар, белешмәләрнең туры килмәү очраклары ачыкланса, җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүче зат, лицензиат адресына, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп яки үтемле башка ысул белән

нигезле таләп алынган көннән башлап ун эш көне эчендә планнан тыш документар тикшерү уздыру барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән, хат (нигезле таләп) җибәрә.

Хатка (нигезле таләпкә) планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкның мөһер белән таныкланган күчермәсе теркәлә.

Җаваплы башкаручы үзенә карата тикшерү уздырыла торган лицензия алырга теләүче заттан, лицензиаттан әлеге Регламентның 1 һәм 2 таблицаларында күрсәтелгән, кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

Зарурлык булганда җаваплы башкаручы, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

Җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүченең, лицензиатның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштыра.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрелә башлаганнан соң сигез эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: Министрлык карамагында булган, җаваплы башкаручы тарафыннан каралган документлар һәм (яки) мәгълүмат; лицензия алырга теләүче зат, лицензиат адресына карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән җибәрелгән хат (нигезле таләп); лицензия контролен үткәрү максатлары өчен башка органнардан алынган, кирәкле белешмәләр һәм документлар.

Хат (нигезле таләп) җибәрү Министрлыкта эш алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Министрлыкка тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

5.35. Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат әлеге хатта (нигезле таләптә) күрсәтелгән документларны мөһер (ул булган очракта) белән һәм лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның имзасы белән тиешенчә таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырырга тиеш. Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат хатта (нигезле таләптә) күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Министрлыкка тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең Министрлык карамагындагы документларның белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы лицензия алырга теләүче зат, лицензиат Министрлыкка элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Үтәү вакыты: нигезле таләп алынган көннән соң ун эш көне эчендә.

5.36. Җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүче затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты, вәкаләтле вәкиле тарафыннан тапшырылган, элегрәк бирелгән документларның төгәл булуын раслый торган аңлатмаларны һәм документларны карарга тиеш.

Тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшергәннән соң, яисә аңлатмалар булмаганда, зарури таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, Министрлыкның вазыйфаи затлары күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Җаваплы башкаручы күчмә тикшерү үткәрү зарурлыгы яки мондый ихтыяҗ булмавы турында карар кабул итә. Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан бирелгән аңлатмаларны һәм (яки) документларны карау барышында лицензия таләпләрен бозу билгеләренең билгеләнүе күчмә тикшерү уздыру зарурлыгы турында карарлар кабул итү критериясе булып тора, алар әлеге Регламентның 5.41 пункты нигезендә күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә.

Күчмә тикшерү үткәргәндә лицензия алырга теләүче заттан, лицензиаттан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.

Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты әзерли.

Үтәү вакыты: аңлатмалар һәм (яки) документлар алыну яисә документар тикшерү актын рәсмиләштерү көненнән соң ике эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан каралган, лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан тапшырылган аңлатмалар һәм (яки) документлар; кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.37. Документар тикшерү уздырганда Министрлык лицензия алырга теләүче заттан, лицензиаттан документар тикшерү предметына карамый торган белешмәләр һәм документлар таләп итәргә хокуклы түгел.

5.38. Планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктларында билгеләнгән тәртиптә планнан тыш документар тикшерү акты төзи.

5.39. Үзләренә карата тикшерү уздырылган лицензия алырга теләүче зат, лицензиат, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән белән килешмәгән очракта, әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка ризасызлыклар тапшырырга хокуклы.

5.40. «Планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасының үтәү нәтиҗәсе билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның рәсми сайтында, «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә (294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 1.1 пункты нигезендә, шул исәптән лицензия бирү турында гариза тапшырган лицензия алырга теләүче затка, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза тапшырган лицензиатка карата үткәрелә торган планнан тыш тикшерүләрдән тыш).

## «ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.41. «Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса.

Күчмә тикшерү документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракларда уздырыла:

1) лицензия алырга теләүченең, лицензиатның Министрлык карамагындагы документларындагы белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуына инану;

2) лицензия алырга теләүченең, лицензиат эшчәнлегенең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен контрольлек буенча тиешле чара үткәрмичә бәяләү.

5.42. Лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат тарафыннан эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен гамәлгә ашырганда куллану күздә тотылган җир кишәрлекләренең, бүлмәләрнең, биналарның, корылмаларның, техник чараларның, җайланмаларның, башка объектларның торышы һәм лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәткәрләр булуы, әлеге объектларның һәм хезмәткәрләрнең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү максатларында, лицензия алырга теләүче затка яки лицензиатка карата 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 7 һәм 9 өлешләрендә каралган очракларда планнан тыш күчмә тикшерү уздыру предметы булып тора.

99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 10 өлешендә каралган планнан тыш күчмә тикшерүләр предметы булып лицензиат документларында аның эшчәнлеге, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен башкарганда файдаланыла торган җир кишәрлекләренең, бүлмәләрнең, биналарның, корылмаларның, техник чараларның, җайланмаларның, башка объектларның торышы турындагы белешмәләр, лицензиат хезмәткәрләренең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең, лицензия таләпләрен үтәү, лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәү буенча лицензиат тарафыннан күрелә торган чараларның лицензия таләпләренә туры килүе тора.

5.43. Күчмә (планлысы да, планнан тышы да) тикшерү лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның эшчәнлек төрен фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

5.44. Планнан тыш күчмә тикшерү әлеге Регламентның 5.14 пунктында күрсәтелгән гамәлләр тәртибе нигезендә башкарыла.

5.45. Әлеге Регламентның 2.15 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, Бүлек җитәкчесе әлеге Регламентның 5.15 пункты нигезендә планнан тыш күчмә тикшерү үткәргән өчен җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.46. Җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли һәм аны министрга (министр урынбасарына) кул куюга җибәрә.

Тикшерү үткәрү турында боерыкның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Үтәү вакыты: киләсе эш көне дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык.

5.47. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән очрак нигез булып торса, җаваплы башкаручы:

- лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына гариза әзерли һәм аны министрдан (министр урынбасарыннан) имзалата (планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турындагы гариза формасы Россия Икътисадый министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

- планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турындагы гаризаны лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында юллый. Бу гаризага планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган белешмәләре булган документлар теркәлә.

Алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата планнан тыш тикшерүләр уздыруны прокуратура органнары белән килештерү тәртибе 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 өлеше һәм Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү уздыру нигезе булып гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган, илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салу, табигый һәм техноген характерлы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе, лицензия таләпләре бозылу очракларына тап булу торса, мондый бозуларны кылу мизгеленә кичектергесез чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә, гаризаны һәм аңа теркәлә торган, планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында Министрлык боерыгы күчермәсен һәм аны үткәрү өчен нигез булып хезмәт иткән белешмәләрне үз эченә алган документларны прокуратура органнарына егерме дүрт сәгать эчендә җибәрү юлы белән, прокуратура органнарына контрольлек чараларының уздырылуы турында хәбәр итеп, Министрлык планнан тыш күчмә тикшерү уздыруга кичекмәстән керешергә хокуклы. Бу очракта прокурор яки аның урынбасары тиешле документлар алынган көнне планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул итә.

Үтәү вакыты: лицензиатка планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыкка кул куелган көнне.

Эш нәтиҗәсе: прокуратура органына җибәрелгән планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза.

5.48. Җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында (үткәрү нигезләре әлеге Регламентның 2.15 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш) аны үткәрә башлаганчыга кадәр кимендә егерме дүрт сәгать алдан теләсә нинди мөмкин булган ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яки лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан Министрлыкка элегрәк тапшырылган булса, лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның электрон почта адресына юлланган электрон документ рәвешендә дә хәбәр итә.

Министрлык әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерүне лицензиатка алдан хәбәр җибәрмичә генә дә үткәрергә хокуклы.

Үтәү вакыты: лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка тикшерү уздыра башлаганчы кимендә егерме дүрт сәгать алдан хәбәр ителергә тиеш.

Эш нәтиҗәсе: лицензиатка тикшерү үткәрү турында хәбәр итү (лицензиатка җибәрелгән тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе).

5.49. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү әлеге Регламентның 5.18-5.20 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.50. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә башкарыла.

Яңа ачыкланган бозулар, шулай ук системалы характерда булган хокук бозу очраклары зарури тәртиптә теркәлә.

Планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештереп башкарылса, планнан тыш акт күчермәсе  күчмә тикшерү тикшерү акты төзелгәннән соң биш эш көне эчендә прокуратура органына җибәрелә.

5.51. Җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.23 пункты нигезендә тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) планнан тыш тикшерү турында язу терки.

5.52. Үзләренә карата тикшерү уздырылган лицензия алырга теләүче зат, лицензиат, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән белән килешмәгән очракта, әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка ризасызлыклар тапшырырга хокуклы.

5.53. Әгәр лицензиат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең булмый торуы сәбәпле, яисә лицензиатның фактта эшчәнлегенең гамәлгә ашырылмавы сәбәпле, яисә лицензиат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының, вәкаләтле вәкиленең тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты, тикшерүне уздыруның мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, аны уздыруның мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу

очракта Министрлык тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге турында акт төзелгәннән соң өч ай эчендә мондый лицензиатларга карата, лицензиатка алдан хәбәр итмичә, планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.54. «Лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасының үтәү нәтиҗәсе билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның рәсми сайтында, «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәлә (294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 1.1 пункты нигезендә, шул исәптән лицензия бирү турында гариза тапшырган лицензия алырга теләүче затка, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза тапшырган лицензиатка карата үткәрелә торган планнан тыш тикшерүләрдән тыш).

## «ЛИЦЕНЗИЯ ТАЛӘПЛӘРЕ БОЗЫЛУ ОЧРАКЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.55. Тикшерүләр уздырганда лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең бозылу очракларының ачыклануы административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып тора.

5.56. Административ процедура Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- лицензия таләпләрен, шул исәптән лицензия таләпләрен тупас бозу очракларын бетерү турында күрсәтмә чыгару;
- ачыкланган бозулар турында белешмәләрне вәкаләтле органнарга җибәрү;
- лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору, яңарту турында карар кабул итү;
- лицензияне гамәлдән чыгару турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү.

5.57. Тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензия таләпләрен, шул исәптән лицензия таләпләрен тупас бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яки) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган таләпләрне исәпкә алып, әлеге Регламентның 5.21 пунктында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән, тиешле чараларны уздыру турында күрсәтмә бирә.

Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора, тикшерү акты белән бергә рәсмиләштерелә һәм лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү беткәннән соң турыдан-туры тикшерү акты белән бергә тапшырыла (җибәрелә).

Күрсәтмә әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән формадагы бланкта рәсмиләштерелә.

Җаваплы башкаручы бирелгән күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылык турында лицензиат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә хәбәр җиткерергә тиеш.

5.58. Кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген башкарганда лицензия таләпләрен тупас бозу исемлеге Лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә (әлеге Регламентның 2.16 пункты).

5.59. Әлеге Регламентның 2.15 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча, ягъни лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең тупас бозылу фактлары турында мәгълүмат килгән очракта планнан тыш күчмә тикшерү уздыру мондый тикшерү уздыруны билгеләнгән тәртиптә лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң һәм лицензиатка алдан хәбәр юлламыйча гына гамәлгә ашырыла.

5.60. Күрсәтмә алган лицензиат ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен билгеләнгән срокта Министрлыкка ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында мәгълүмат, шулай ук мондый җитешсезлекләрне бетерү максатларында күрсәтмәнең һәр пункты буенча чаралар үткәрүне раслаучы документларны тапшырырга тиеш.

5.61. Лицензиат, ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн эчендә Министрлыкка ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә яисә аның аерым нигезләмәләренә язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта лицензиат мондый ризасызлыкларга әлеге ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

5.62. Күрсәтмә үтәлешен тикшерүне үткәргән һәм күрсәтмәне рәсмиләштергән җаваплы башкаручы билгеләнгән вакытта контрольдә тота.

5.63. Күрсәтмәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү срогы чыккач яисә лицензиаттан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында мәгълүмат алынган очракта, җаваплы башкаручы, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне бәяләү мөмкинлегенә карап, планнан тыш документар яки планнан тыш тикшерү әзерли һәм үткәрә. Тикшерү әлеге Регламентның «Планнан тыш документар тикшерү үткәрү» яки «Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедуралары нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтмә үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре әлеге Регламентның 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә рәсмиләштерелә.

5.64. Лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турындагы күрсәтмә үтәлешен тикшерү предметы булып, бары тик Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.

5.65. Планлы тикшерү барышында Россия Федерациясенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты тарафыннан Россия Федерациясенең законнарын бозу очраклары ачыклаганда, Министрлыкның вазыйфаи затлары алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмә бирә. Хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең күчермәсе планлы тикшерүне үткәрү нәтиҗәләре турында акт төзелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яисә аның вәкиленә имзалатып тапшырыла яисә мондый күрсәтмәне алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты тарафыннан алу датасын раслаучы башка ысул белән тапшырыла. Әгәр күрсәтелгән ысуллар белән закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәне алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яисә аның вәкиленә тапшыру мөмкин булмаса, ул почта

аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм аны җибәргәннән соң алты көн узгач алынган дип санала.

Министрлык хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелгән көннән соң ике ай үткәч, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына планнан тыш тикшерү үткәрә. Бозуларны бетерү өчен ике айдан артык вакыт кирәк булса, планнан тыш тикшерү бозуларны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокларда, әмма мондый күрсәтмә чыгарылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

Резидент тарафыннан планнан тыш тикшерү уздырганчыга кадәр бозуларны бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, эшчәнлекне тормышка ашыру турындагы килешү өзелергә мөмкин һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы, вәкаләтле федераль орган гаризасы нигезендә, суд карары нигезендә туктатылырга мөмкин.

5.66. Тикшерүләр, шул исәптән тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан «Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, тикшерүләрне исәпкә алу журналында кертелә.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ҮТӘЛЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

6.1. Министрлыктагы вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту министр (министр урынбасары) тарафыннан башкарыла.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә лицензия контролен үтәү буенча гамәлләрнең срокларын, эзлеклелеген, Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту министр урынбасары һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.4. Министрлыкның вазыйфаи затларының вәкаләтләре, шул исәптән әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру буенча да, Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, вазыйфаи инструкцияләрдә билгеләнә.

6.5. Министрлык тарафыннан дәүләт функциясен үтәүнең тулылы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелүче затларның хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләре булган мәнфәгатьле затларның мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Тикшерүләр Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда дәүләт функциясен үтәгәндә җитешсезлек-

ләрнең булмавы яки ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

6.6. Дәүләт функциясенең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планлы тикшерүләр Министрлыкның агымдагы елга эш планы нигезендә үткәрелә, ул Министрлыкның дәүләт функциясен башкаруга вәкаләтле идарәсе җитәкчесе тарафыннан әлеге планга кертелә.

6.7. Дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерүләр Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) гражданнарның шикаятьләре (дәгъвалары) нигезендә үткәрелә.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, дәүләт функциясен башкарганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җитешсезлекләр җибәрелүе ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Дәүләт функциясенең үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту берләшмәләр һәм оешмаларның уставлары, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Министрлыкка тапшырылган, дәүләт функциясен үтәү буенча иҗтимагый контрольлек нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

6.10. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлары дәүләт функциясен үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен җаваплы була.

Министрлык вазыйфаи затларының җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи инструкцияләрендә беркетелә.

## 7. МИНИСТРЛЫК, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Лицензия алырга теләүче затның яки лицензиатның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, мәнфәгатьле башка затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) дәүләт функциясен үтәү барышында Министрлык, аның вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән, юридик затларның, шәхси эшкуарларның хокуклары бозылуга китергән карарларга һәм аларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерергә хокуклы.

7.2. Шикаять Министрлыкка язмача кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла. Шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, шул исәптән Министрлыкның рәсми сайтын кулланып та, җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене Министрлыкта шәхси кабул иткән вакытта да кабул ителергә мөмкин.

7.3. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) Министрлыкның атамасы яки тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә тиешле затның вазыйфасы;

б) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать

итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

в) шикаятьнең асылы буенча эчтәлеге (дәүләт функциясен үтәү барышында Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән, шикаять белдерелә торган гамәлләре (гамәл кылмавы), карарлары;

г) шәхси имза һәм дата.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләре теркәлергә мөмкин.

7.4. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып дәүләт функциясен үтәү барышында катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән карарлары тора.

7.5. Министрлыкка яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиеш. Шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карауны туктату өчен нигезләр каралмаган.

7.6. Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның атамасы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр бу шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьтә аның асылы буенча, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, инде берничә мәртәбә язмача җавап бирелгән сорау бәян ителсә һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, министр,

Министрлыкның вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле зат, әлеге шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Министрлыкка яисә Министрлыкның шул бер үк вазыйфаи затына җибәрелгән булу шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Министрлыкка яки Министрлыкның вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган Министрлык рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә әлеге белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Министрлыкка яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.7. Мөрәҗәгать итүчедән яисә аның вәкаләтле вәкиленнән Министрлыкка шикаять алынуы Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

7.8. Министрлыкка яисә Министрлыкның вазыйфаи затына аларның компетенцияләре нигезендә килгән шикаять Министрлыкта теркәлгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә карала.

7.9. Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять министрга, министр урынбасарына җибәрелергә мөмкин.

Министрлыкның, министрның гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.10. Лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат, мәнфәгатьле башка затлар шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алу хокукына ия. Мондый төрдәге мәгълүмат һәм документларны алу өчен лицензия алырга теләүче зат яки лицензиат Министрлык адресына кәгазьдә яисә электрон формада язмача рәсми мөрәҗәгать юлларга тиеш. Министрлыкның вазыйфаи затлары сорала торган белешмәләрне һәм документларны мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң 30 календарь көне эчендә бирергә бурычлы.

7.11. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) лицензия контролен гамәлгә ашыру барышында Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының кабул ителгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

- хезмәт тикшерүе барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата чаралар күрү;

- хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган лицензия алырга теләүче затка яки лицензиатка Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында мондый чараларны күргән көннән башлап ун көн эчендә язмача формада хәбәр итү;

2) лицензия алырга теләүче затның яисә лицензиатның лицензия контролен гамәлгә ашыру барышында Министрлыкның, аның вазыйфаи затлары кабул иткән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрен, мондый карарны мотивлаштырылган рәвештә нигезләп, канәгатьләндермичә калдыру.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

# Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

## КҮРСӘТМӘ №

ачыкланган бозуларны бетерү турында

Казан шәһәре «__»__________20__ел.

Бирелде

________________________________________________________________________

(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

Юридик зат урнашкан урын (шәхси эшкуар яшәгән урын адресы)
____________________________________________________________________

Салым түләүченең тәңгәллек номеры (ИНН) ______________________________

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язуың төп дәүләт теркәү номеры
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «___»_____________ 20__ ел, № ___ боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Административ реформа мәсьәләләре идарәсенең лицензияләү бүлеге вазыйфаи затлары: ____________________________________________,

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

территориаль аерымланган объектларга планлы тикшерү үткәрелде
_______________________________________________________________________,

(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

урнашкан адреслары: ______________________________________________.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча «___»_____________ 20__ №___акт төзелде, имзаланды
_______________________________________________________________________.

(юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Тикшерү актының икенче нөсхәсе имзалатып алынды ________________________
______________________________________________________________________.
(юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Тикшерү барышында: ___________________________________________________.
(норматив хокукый актны күрсәтеп, бозуларның эчтәлеге)

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлеше, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күрсәтмә бирәм:

1. Лицензия таләпләрен үтәүне раслап, югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерергә:

______________________________________________________________________
(лицензия таләпләре исемлеге)

2. 20___ елның «___» _____________ кадәр әлеге күрсәтмә үтәлеше турында язма рәвештә хәбәр итәргә һәм аның үтәлешен раслый торган документларның күчермәләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшырырга.

Күрсәтмәгә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Әлеге күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясының 1 өлеше нигезендә җаваплылык каралган.

Күрсәтмәне төзегән
вазыйфаи зат

_______________ ___________________________________ ______________________
(вазыйфа) (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза, дата)

Күрсәтмәне алды:

_________________ _________________________ ____________________________
(вазыйфа) (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза, тапшыру датасы)


______________________________________________________________________
(юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документның датасы һәм номеры)


Күрсәтмә почта аша җибәрелде:

_________________________________________________________
(дата, заказлы хат, белдерү номеры)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламентына 2 нче кушымта

# ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА




Лицензия таләпләре бозылу фактларын билгеләү
Лицензия таләпләре бозылу фактларын билгеләү
Тикшерү тәмамланган көнне ике нөсхәдә тикшерү акты төзү һәм имзалау
Лицензия таләпләре бозылу очракларын бетерү турында күрсәтмә төзү
Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хакимияте органнарына мәгълүмат җибәрү
Лицензия алырга теләүче затны, лицензиатны (аларның вәкилләрен), шулай ук лицензия контроле буенча чаралар үткәргәндә катнашкан затларны акт (лицензия таләпләрен бозу очракларын бетерү турында күрсәтмә) белән таныштыру
Лицензия алырга теләүче затның, лицензиатның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә , кушымталарының күчермәләре белән, тикшерү акты нөсхәсен тикшерү акты белән танышып чыгу турында яки танышып чыгудан баш тарту турында имзалатып тапшыру яки, кулга тапшыру турында белдереп,
Җаваплы башкаручы тарафыннан тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) күчмә тикшерү турында язу теркәү

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясе башкаруның административ регламентына 3 нче кушымта

ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫСАЛАРЫНДА МИНИСТРЛЫК ТАРАФЫННАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТҮЧЕ БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН СОРАТЫЛА ТОРГАН ӘЛЕГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

| Соратыла торган документның аталышы һәм (яисә) соратыла торган мәгълүмат | Соратыла торган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма |
|---|---|
| 1 | 2 |
| лицензия алырга теләүче затның (лицензиатның) милек хокукында яки башка законлы нигездә җир участогы, биналары, корылмалары булуын раслаучы документлар | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе |
| Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе |